| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

07.11.2025 Казан ш. 4053-р

Бүлгеч газүткәргечнең саклау зонасын үзгәртү һәм Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт министрлыгының «Татарстан Республикасының «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге, Тукай, Минзәлә муниципаль районнары территориясендә бүлгеч челтәрнең саклау зонасы чикләрен билгеләү турында» 17.04.2019 № 1235-р карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 ст., «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, һәм «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә, «Татарстан Республикасының пространство мәгълүматлары фонды» ДБУ хатын исәпкә алып (26.09.2025 № 01А-04/1995) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып:

1. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт министрлыгының «Татарстан Республикасының «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге, Тукай, Минзәлә муниципаль районнары территориясендә бүлгеч челтәрнең саклау

зонасы чикләрен билгеләү турында» 17.04.2019 № 1235-р карары (алга таба - № 1235-р карар) белән Минзәлә муниципаль районы территориясендә урнаштырылган, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ милкендә булган, 7099 инвентарь номерлы, 1616:28-6.752 реестр номерлы бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасын трасса үзгәртелеп газүткәргеч үзгәртеп ясалу сәбәпле территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүматка, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп, үзгәртергә. Инвентарь номеры 7099 булган бүлгеч газүткәргечнең саклык зонасының озынлыгы гомуми мәйданы 468 кв.м.лы территория рәвешендә 117 м.ны тәшкил итә.

2. Инвентарь номеры 7099 булган газ бүлгеч газүткәргечне эксплуатацияләү срогында назүткәргечнең саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлеге нигезендә № 1235-р Карарга (Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт министрлыгының 22.10.2025 № 3768-р карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) «6781», «27123» цифрларын тиешле тәртиптә «16534», «66135» цифрларына алыштырып үзгәрешләр кертергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**